**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябр 2024 г № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 29 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 1-55нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 56-124нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2024 елның 31 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Полевая урамы буенча 1-59нчы йортлардан, Үзәк тыкрыгы буенча 1-14нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2025 елда Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
2) урамнарны яктырту җайланмасы.
3) су белән тәэмин итү һәм су азыгып җибәрү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева